**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 3 октябрь | № 710

г. Казань

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге ФЗ-68 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге турында» 2015 ел, 24 декабрь, 1418 нче карары, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 ел, 26 февраль, 119 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеген расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\710.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 3 октябрь, 710 нчы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеге**

Министр урынбасары (халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара, муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге мәсьәләләренә җитәкчелек итә);

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге баш белгече;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге I категория белгече;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең бүлекчә башлыгы;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге бүлекчәсенең гражданнар оборонасы белгече (әйдәүче белгеч).

---